«Раслыйм»

«Сэлэт» ТРЯИФ
Генераль директоры,
ТФА академигы,
КФУ профессоры

Җ.Ш. Сөләйманов

_______________ 2020 ел

# НИГЕЗЛӘМӘ

## Р.Г. Бохараев исемдәге Республикакүләм IT-хакатон («Бу-Хакатон»)

### 1. Гомуми нигезләмә

1.1. Р.Г. Бохараев исемдәге Республикакүләм IT-хакатон (алга таба – Бу-Хакатон) Татарстан Республикасы «Сэлэт» яшьләр иҗтимагый фонды (алга таба – «Сэлэт» ТРЯИФ) тарафыннан «Сэлэт» яшьләр үзәге дәүләт бюджет учреждениясе (алга таба – ЯҮ «Сэлэт»), ТФА Гамәли семиотика институты, «Школа 21», ИТИС КФУ, ЗАО «Телеком 21» белән берлектә һәм Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы, Казан федераль (Идел буе) университеты катнашында үткәрелә.

1.2. Бу-Хакатон ярышында санак программалары эшләүчеләр, шулай ук, дизайнерлар, маркетологлар, продюсерлар, менеджерлар һәм башка белгечләр белән берлектә, когнитив технологияләр, өстәмә һәм виртуаль чынбарлык технологияләре, мобиль эшләнмәләр, мультимедиа һ.б. мөмкинлекләр кулланып, белем бирү сегментындагы продуктларның прототипларын эшлиләр.

1.3. Бу-Хакатонны планлаштыру һәм уздыру өчен оештыру комитеты төзелә, аның белән «Сәләт» ТРМФ җитәкчелек итә.

2. Бу-Хакатонның максаты:

2.1. Мәктәп укучылары һәм студентлар арасында санак программалары төзү һәм мәгълүмати технологияләрне өйрәнүне һәм куллануны популярлаштыру.

2.2. IT-белем бирү һәм куллану даирәсен киңәйтү, балалар һәм яшьләрнең цифрлы технологияләргә карата кызыксынуларын үстерү өчен традицион булмаган формалар һәм алымнар (конкурслар, уеннар һ.б.) куллану.

2.3. Мәктәп укучыларына математика-информатика юнәлешендә үз сәләтләрен һәм фәнни потенциалларын ачуда һәм гамәлгә ашыруда методик ярдәм күрсәтү.

2.4. Информатика һәм исәпләү техникасы, теоретик кибернетика, ясалма интеллект өлкәләре үсешенә, шулай ук кибермохиттә татар телен куллану өчен программалар эшләүгә зур өлеш керткән, ТР Фәннәр академиясенең Гамәли семиотика институтына нигез салучыларның берсе булган зур галим, күпкырлы шәхес һәм Остаз, физика-математика фәннәре һәм техник фәннәр докторы, профессор Рәис Гатич Бохараевның исемен яшьләргә җиткерү.

3.Бу-Хакатонның бурычлары:

3.1. Татар телен үстерү, укучылар һәм студентлар арасында популярлаштыру өчен IT-продуктлар булдыру.

3.2. Программалаштыру өлкәсендә татар телен актив куллану өчен мотивацион шартлар тудыру.

3.3. Рәис Гата улы Бохараевның фәнни һәм фәнни-гамәли мирасын өйрәнү өчен мәйданчык булдыру.

3.4. Фән белән кызыксынучы сәләтле укучыларны ачыклау, алга таба үсү өчен мөмкинлекләр ачу.

3.5. Укучыларның иҗади, танып-белү һәм интеллектуаль инициативасын активлаштыру, аларны төрле фәнни өлкәләрдәге, бигрәк тә, дисциплинаара өлкәләрдәге, тикшеренүләргә җәлеп итү.

3.6. Интеллектуаль-иҗади эшчәнлекне популярлаштыру, укучылар арасында математик фәннәргә кызыксыну уяту.

3.7. Укучылар белән эшләргә галимнәр, фәнни-тикшеренү институтлары һәм югары уку йортлары хезмәткәрләрен җәлеп итү;

3.8. Укучыларның тикшеренүләргә нигезләнгән белем бирү программаларын һәм методикаларын үстерү.

4. Төп юнәлеш

4.1. Бу-Хакатон мәктәп укучылары һәм студентлар арасында татар телен популярлаштыру һәм үстерү өчен проектлар базасын булдыру һәм IT-продуктларны гамәлгә ашыру өчен үткәрелә.

5. Бу-Хакатонда катнашучылар һәм эшләрне тәкъдим итү тәртибе

5.1. Бу-Хакатонда Татарстан Республикасы гомуми белем бирү учреждениеләренең 8-11 сыйныф укучылары, шулай ук Россия Федерациясе төбәкләре һәм чит илләрдән югары уку йортларында һәм көллиятләрдә 1-4 курсларда укучы студентлар катнаша ала. Бу-Хакатонда составына кимендә - ике, күп дигәндә, дүрт укучы кергән командалар катнаша. Командалар 14-17 һәм 18-22 яшьләрдәге төркемнәр арасында, тутырылган гариза һәм катнашучыларның яше нигезендә формалаша.
5.2. Бу-Хакатонда катнашу өчен 2020 елның 27 маеннан 2020 елның 10 сентябренә кадәр selet.biz сайтында теркәлү узарга кирәк.

6. Бу-Хакатонны үткәрү вакыты һәм тәртибе

6.1. Бу-Хакатонны үткәрү датасы: 2020 елның 26 сентябре.
Бу-Хакатонны үткәрү урыны: Казан шәһәре, Островский ур., 23, Сәләт Йорты.
6.2. Бу-Хакатон программасы нигезләмәнең 6.8 пунктында тәкъдим ителгән программа буенча тормышка ашырыла.
6.3. Хакатонның бурычы: Хакатон темасына туры килгән проблеманы билгеләү (п.2.1.), әлеге проблеманы хәл итү юлын күрсәткән продукт булдыру (кушымта, уен, сайт, презентация, анимация).
6.4. Проектларны эшләү ике этаптан тора. Беренче этапның нәтиҗәсе буларак проектны башкару планы төзелә (проблема һәм аны хәл итү юллары тасвирлана; командаларга исем кушыла, команда эчендә рольләр билгеләнә). Икенче этап нәтиҗәсе – эшләнелгән продукт яки продукт прототипы.
6.5. Командалар үз проектларын Жюри әгъзаларына тәкъдим итәләр (команданы тәкъдим итү; проектның исеме; проблеманы күрсәтү; чишү) һәм продуктның эшкә яраклыгын күрсәтәләр (чыгыш ясау регламенты - 7 минуттан да артык түгел: 3 минут - чыгыш, 2 минут - прототипны күрсәтү һәм 2 минут - сорауларга җаваплар).
6.6. Катнашучылар трансферы һәм аларны ашату катнашучы якның үз хисабына башкарыла.
6.7. Катнашучы командаларның тулбоксы: һәр катнашучы өчен билгеләнгән программа белән тәэмин ителгән ноутбук, челтәр фильтры һәм башка җайланмалар.
6.8.

| Вакыты | Чара | Уздыру урыны |
|---|---|---|
| Чара | | |
| 27 май 2020 –<br><br>10 сентябрь | Бу-Хакатонда катнашучыларны электрон теркәү | www.selet.biz |

| | | |
|---|---|---|
| 2020 | | |
| 10-20 сентябрь 2020 | Бу-Хакатонның читтән торып катнашу этабы | Сәләт йорты (Казан шәһәре, Островский ур., 23 йорт) |
| 22 сентябрь 2020 | Читтән торып үткәрелгән этапның нәтиҗәләрен тәкъдим итү | www.selet.biz |
| **Килеп катнашу этабы** | | |
| 26 сентябрь 2020 | 10.00-11.00 катнашучыларны теркәү<br>11.00-12.00 Бу-Хакатонның ачылу тантанасы. Проф. Бохараев Р. Г. укучыларының чыгышы /пленар утырыш<br>12.00 – 14.00 1-нче конкурс туры<br>14.00-15.00 төшке аш<br>15.00 – 17.00 2-нче конкурс туры<br>17.00-18.30 эшләрне тәкъдим итү<br>18.30-19.00 җиңүчеләрне бүләкләү, сертификатлар тапшыру | Сәләт йорты (Казан шәһәре, Островский ур., 23 йорт) |

7. Бу-Хакатонга йомгаклау ясау тәртибе

7.1. Бу-Хакатон кысаларында башкарылган биремнәрне экспертлар жюрие бәяли, аның составына Казан федераль университеты һәм ТФА Гамәли семиотика институты белгечләре керә.

7.2. Проектларны бәяләү дүрт төп юнәлеш буенча башкарыла;

– фикер-мәгънә;
– продукт (функциональлек, техник башкарылышы);
– менеджмент (рольләрне бүлү, таймингка сыешу);
– дизайн (когнитивлык, башкару сыйфаты);
– чыгыш (теманы ачып бирүнең тулылыгы, чыгыш ясау сыйфаты).

7.3. Конкурста бәяләү критерийлары нигезендә иң күп балл җыйган командалар, шулай ук аерым затлар (номинантлар) җиңүче дип танылa. Һәр пункт 10 баллы система буенча бәяләнә.

7.4. Бу-Хакатонның барлык катнашучыларына сертификатлар тапшырыла. Җиңүчеләр дипломнар белән бүләкләнә.

8. Оештыру комитеты белән элемтәгә керү өчен мәгълүмат

8.1. Оештыру комитеты адресы: Сәләт йорты, Казан шәһәре, Островский урамы, 23-нче йорт. Электрон почта: xat@selet.biz. Белешмәләр өчен телефон: +7 834 292 16 00.